Шифр ТЯ11-11

**Задания регионального этапа**
**Всероссийской олимпиады школьников**
**по татарской литературе**
**2017-2018 учебный год**
**11 класс**

Уважаемый участник!

Время проведения олимпиады по татарской литературе в 9-11 классах – 180 минут. Максимальное количество баллов – 50 баллов.

Ответы на задания 1 *части* заносятся в таблицу ответов.

| Инструкция по выполнению работы |
|---|
| При выполнении заданий в Таблице ответов под номером выполняемого вами задания поставьте знак «Х» в клеточку, которая соответствует букве выбранного вами ответа. |

Таблица ответов

| | 1.1 | 1.2 | 1.3 | 1.4 | 1.5 | 1.6 | 1.7 | 1.8 | 1.9 | 1.10 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1) | | | | | | | | | | |
| 2) | X + | | | | X + | X + | | X + | | |
| 3) | | X + | X + | X + | | | | | X + | X + |
| 4) | | | | | | | X + | | | |
| Задания по 1 баллу | | | | | | | | | | |

10б

| 1 | Тестлар (дөрес җавапны билгеләгез) | 10 |
|---|---|---|
| 1.1 | Кайсы жанр лирик төргә карый?<br>1) Нәсер;<br>2) Шигырь;<br>3) Хикәя. | 1 |
| 1.2 | Кайсы шагыйрьне “Туган як җырчысы” дип атыйлар?<br>1) Р.Фәйзуллин;<br>2) Р.Гаташ;<br>3) С.Хәким;<br>4) Р.Миңнуллин. | 1 |
| 1.3 | “Шәхес культы” фаҗигаләрен кичергән шагыйрь:<br>1) М.Болгари;<br>2) С.Сараи;<br>3) Х.Туфан;<br>4) Г.Утыз Имәни. | 1 |
| 1.4 | Ф.Кәримнең “Кыңгыраулы яшел гармун” әсәре ул –<br>1) Шигырь; | 1 |

| | | |
|---|---|---|
| | 2) Хикәя;<br>3) Поэма. | |
| 1.5 | Г. Әпсәләмовның “Ак чәчәкләр” романында сүз нинди һөнәр ияләре турында бара?<br>1) Бакчачылар;<br>2) Табиблар;<br>3) Укытучылар. | 1 |
| 1.6 | Һ. Такташның “Мәхәббәт тәүбәсе” поэмасында төп тема:<br>1) Мәхәббәтнең үлемсезлеге;<br>2) Мәхәббәт һәм җаваплылык;<br>3) Мәхәббәт һәм хезмәт берлелеге. | 1 |
| 1.7 | “Беренче театр” әсәренең авторы:<br>1) М.Фәйзи;<br>2) К.Тинчурин;<br>3) Ш.Камал;<br>4) Г.Камал. | 1 |
| 1.8 | Кайсы әсәр Г. Бәшировның түгел:<br>1) “Намус”<br>2) “Акчарлаклар”<br>3) “Туган ягым яшел бишек” | 1 |
| 1.9 | М.Җәлилгә Советлар Союзы Герое исеме бирелде:<br>1) 1945 елда;<br>2) 1965 елда;<br>3) 1956 елда. | 1 |
| 1.10 | Булат Сөләймановның туган авылы<br>1) Сыркыды;<br>2) Кушлавыч;<br>3) Сопра. | 1 |
| 2 | Түбәндә саналган әсәрләрнең жанрларын һәм авторларын күрсәтергә. | 5 |
| | 1) Әтәч менгән читәнгә”<br>Аяз Гыйләҗев – повесть +<br>2) “Хәят”<br>Ф. Әмирхан – повесть +<br>3) “Намус”<br>Г. Баширов – (повесть) роман ⊥<br>4) “Җилкәннәр җилдә сынала”<br>Ф. Яруллин – автобиографик әсәр повесть +<br>5) “Меңнәр, яки гүзәл кыз Хәдичә”<br>З. Бигиев – роман + | 3б |
| 3 | Бирелгән юлларны дәвам итегез, әсәрнең исемен, авторын языгыз. | 20 |
| 3.1 | Җыр өйрәтте мине хөр яшәргә | 5 |

| | | |
|---|---|---|
| | Һәм үләргә кыю ир булып<br>Гомерем минем моңлы бер җыр иде<br>Үлемем дә яңгырар җыр булыр<br>М. Җәлил „Җырларым" | + |
| 3.2 | "Нишлим, сугыш дустым – пистолетым<br>Соңгы сүзен кисәк баш тартты<br>Богау салды дошман кулларыма<br>Һәм хурлыклы юлдан атлатты<br>М. Җәлил „Кичер, илем" | 5<br>+ |
| 3.3 | "Мин төп себер татарымын чыгышым белән<br>Гомер сөрсә монда минем бабаларым<br>Чал Иртышның үзе кебек борынгыдан<br>Яшәп килә татар балалары.<br>Б. Сөләйманов „Мин төп себер татарымын чыгышым белән" | 5<br>+ |
| 3.4 | "И сабыйлар! Эшләгез сез, иң мокатдәс нәрсә эш<br>Эш агачы һәрвакыт бик юмарт, китерер җимеш<br>Яшь чагыңда күп тырышсаң, эшкә бирсәң чын күңел<br>Картлыгыңның картлыгыңны бик тыныч һәм бик җиңел<br>Г. Тукай „Эшкә өндәү" | 5<br>+ (20б) |
| 4 | 1) Түбәндә китерелгән өзекне укыгыз, драманың авторын һәм исемен күрсәтегез.<br>2) Әлеге өзектә табигать сурәтен ачыклаган әдәби төшенчәне языгыз;<br>3) Әсәрдә әлеге төшне кемнең күрүен атагыз.<br><br>«Юк, Сәрвәр, безгә кавышу насыйп булмас. ... Безне аерырлар. Мин төшемдә шулай күрдем. Өч тапкыр шул бер үк төшне күрдем. Күзгә караңгы төн, имеш. Күктәге йолдызлар шундый яктылар, имеш. Бер урында бик күп егетләр җыелганнар икән дә һәркайсы үзенә берәр йолдыз алганнар икән. Син дә шул арада үзеңә йолдыз сайлагансың, ди. Мәхдүм дә сайлаган, минем дә йолдызым бар икән. Менә кинәт аждаһа төсле бернәрсә сызгырды да, йолдызларны сүндерә башладылар. Минем йолдызым да сүнде, мәхдүмнең дә, синең йолдыз да сүнде. Тагын бик күп, бик күп егетләрнең йолдызлары сүнеп, күк йөзе корымлы кара таба төсле караңгыланып, каралып калды.<br>Сәрвәр *(елап)*. Җитәр, җитәр, җитәр... Юк, юк, бу – ялган төш, бу дөрес түгел».<br><br>1) „Сүнгән йолдызлар" – К. Тинчурин<br>2) "Бу өзектә табигать сурәтен ачыклаган әдәби төшенчә – аждаһа." пейзаж – | 5<br><br><br><br><br><br><br><br><br><br>(2б.) |

| | | |
|---|---|---|
| | 3) Искәндәр исемле бала. Исмәгыйль | |
| 5 | Алдагы әсәр белән бәйләп, мәхәббәткә тугрылык турында фикер йөртеп, кечкенә инша языгыз.<br><br>Нәрсә ул мәхәббәт? Минем уемча, мәхәббәт - бик олы, йөрәкне җылыта торган хис. Һәр кеше үзендә сизеп алган, һәркемнең дә булган берничә мәхәббәте.<br>К. Тинчуринның „Сүнгән йолдызлар" драмасында бик ачык мәхәббәтнең көчлелеге күренә һәм нәрсәгә баралар аның геройлары бергә булып калу өчен. Сәрвәр үзенең бәхетен - Искәндәрне бушатырга теләми һәм коткарам дигәндә егетен үтереп куя. Ул мондый кайгыны түзәлми үзе дә вафат була, аннан соң Сәрвәрне ярата торган егет тә шулай ук вафат була Искәндәрнең төше дөрес булып чыга. Бу әсәр белән автор безгә күрсәтә әдәби геройларының мәхәббәткә тугрылы калуын.<br>Тагын да шундыйрак әсәр китерел китәм - М. Фәйзинең „Галиябану" драмасы. Анда, кубесинә, Искәндәр, Хәлил һәм Галиябану турында сүз бара. Хәлил белән Галиябану бик яраталар бер берсен, ә Искәндәр аларның арасына кереп, кызны үзенә каратырга тели. Ләкин әсәрнең кайгылы соңы булса да, алар мәхәббәтләренә туры калалар.<br>Минем әйтәсем килә, кешеләр, сезнең мәхәббәтегез булса, сез аны саклагыз һәм бушатмагыз! | 10 |
| | Барлыгы | 50 |

10б

Итого: 47б